# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль район Кәүҗияк авыл җирлеге
Петровка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2022 елның 19 ноябре** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «2022 елның 19 ноябрендә узган гражданнар җыенының "сез 2023 елда һәр балигъ булмаган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе буенча үткәрелгән йомгаклау беркетмәсе төзелде., Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Петровка территориясендә теркәлгән, моннан тыш, I төркем инвалидларыннан, ялгыз яшәүче (80 яшькә житкән), көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, һәм вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү өчен үзарасалым кертергә килешәсезме:

1) Петровка т. п. урамнарын кардан чистарту;
2) Петровка торак пунктында урам утлары объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу, урнаштыру).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 54 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 50 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: җыенда катнашкан 50 кеше «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Петровка торак пунктында халык җыенын уздырылган, халык җыены нәтиҗәләрен- дөрес дип танырга.

2. "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Петровка территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, I төркем инвалидларыннан, ялгыз картлар (80 яшькә җиткән), көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, һәм вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү " мәсьәләсе буенча карар кабул итәргә:

1) Петровка т. п. урамнарын кардан чистарту;
2) Петровка торак пунктында урам утлары объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу, урнаштыру)кабул ителгән.

3. Җыен нәтиҗәләрен Кәүҗияк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы Ф. Ә. Хөснетдинов